ГЛАВА ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«27» июнь, 2024 ел

Алабуга шәһәре

№ 17

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы бүләкләр (награда) белән бүләкләү буенча комиссия төзү турында

Гражданнарны Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, шулай ук Алабуга муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләүгә бәйле мәсьәләләрне алдан карау системасын җайга салу максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы бүләкләр (награда) белән бүләкләү буенча комиссия төзергә (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы бүләкләр (награда) белән бүләкләү буенча комиссия турындагы Нигезләмәне расларга 21 кушымта).

3. Предприятие учреждение һәм оешма җитәкчеләренә, дәүләт органнарының вазифаи затларына, бүләкләү турында үтенеч язуы (тәкъдимнәр) белән мөрәҗәгать итүче гражданнарга әлеге карар белән эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Алабуга муниципаль районы Башлыгының 2006 елның 7 июнендәге 206 номерлы карары барлык кертелгән үзгәрешләр белән үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район Башлыгы Р.М. Нуриев

Алабуга муниципаль районы
Башлыгының 2024 елның
27 июнендәге 17 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы бүләкләр (награда) белән бүләкләү буенча комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Наякшина Анастасия Николаевна | Алабуга муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| 2. | Исланов Роман Леонидович | Алабуга муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| 3. | Галиуллина Диана Андреевна | Алабуга муниципаль районы Советының оештыру бүлеге баш белгече, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| 4. | Миннекаева Гөлүзә Альмер кызы | Алабуга муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы |
| 5. | Курамшин Надир Дамир улы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 7. | Камалова Диләрә Әзһәм кызы | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы |
| 8. | Соколова Светлана Вил кызы | Алабуга район Советы депутаты (килешү буенча) «Алабуга политехника көллияте» ДАҺБУ директоры |
| 9. | Абдуллина Аделя Ильдус кызы | Алабуга шәһәр Советы депутаты (килешү буенча) «Эссен Продакшн АГ» АҖ PR-директоры |
| 10. | Деготьков Александр Анатольевич | Алабуга тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгының фәнни эш буенча генераль директор урынбасары, Алабуга шәһәр Советы депутаты (килешү буенча) |
| 11. | Миңнегулова Әлфия Минһаж кызы | «АлАЗ» җитештерү берләшмәсе» АҖнең кадрлар департаменты директоры (килешү буенча) |
| 12. | Сәфәров Рамил Рәфкать улы | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ССДАУ баш табибы, Алабуга шәһәр Советы депутаты (килешү буенча) |
| 13. | Баганов Геннадий Петрович | Алабуга муниципаль районы ветераннар Советы рәисе (килешү буенча) |

Алабуга муниципаль районы
Башлыгының 2024 елның
27 июнендәге 17 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы бүләкләр (награда) белән бүләкләү буенча комиссия турындагы**
**Нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы бүләкләр (награда) белән бүләкләү комиссиясе (алга таба - комиссия) район Башлыгы каршындагы консультатив орган булып тора һәм Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, шулай ук Алабуга муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләүгә бәйле мәсьәләләрне алдан карау өчен, бүләкләр тапшыру һәм мактаулы исемнәр бирү өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыру максатларында төзелә.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, Алабуга муниципаль районы Башлыгы һәм Алабуга муниципаль районы Советы карарлары һәм бүләкләүне регламентлаштыра торган башка норматив хокукый актлары белән җитәкчелек итә.

3. Комиссиянең төп бурычы Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын, шулай ук Алабуга муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затларны, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре, шулай ук Алабуга муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләүгә объектив якын килүне тәэмин итү турындагы материалларга бәя бирү.

4. Бүләкләү документларын карау нәтиҗәләре буенча комиссия Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарына кергән тәкъдимнәргә бәяләмә бирә, Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, шулай ук Алабуга муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләүгә тапшыра.

5. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итүдә түбәндәгеләргә хокуклы:

- дәүләт, иҗтимагый һәм башка органнардан, оешмалардан һәм вазифаи затлардан Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, шулай ук Алабуга муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләү мәсьәләләренә кагылышлы өстәмә материаллар һәм белешмәләр соратып алырга;

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, шулай

ук Алабуга муниципаль районы бүлəклəре белəн бүлəклəү турында үтенеч язуы тапшырганда закон талəплəрен үтəү турында бəялəмəлəр əзерлəү өчен белгечлəр җəлеп итəргə;

- комиссия утырышында Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының дəүлəт бүлəклəре, шулай ук Алабуга муниципаль районы бүлəклəре белəн бүлəклəү турында үтенеч язуы белəн мөрəҗəгать иткəн оешма, учреждение, предприятие вəкиллəрен тыңларга.

6. Комиссия утырышлары кирəк саен уздырыла. Комиссия утырышының көн тəртибе проекты утырышка кадəр 5 көннəн дə соңга калмыйча комиссия секретаре тарафыннан төзелə. Комиссия утырышының көн тəртибен комиссия рəисе раслый.

7. Комиссия утырышлары, əгəр аларда аның өченче кимендə ике əгъзасы булса, тулы хокуклы.

8. Бүлəклəү турындагы документлар тəкъдим ителə торган датага кадəр кимендə 30 көн кала комиссиягə тапшырыла.

9. Бүлəклəү материалларын комиссия утырышына əзерлəү һəм беркетмəне рəсмилəштерү комиссия секретаре тарафыннан башкарыла.

10. Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучылар санынннан күпчелек тавыш бирү юлы белəн кабул ителə һəм тəкъдим итү характерында була. Комиссия карары беркетмə белəн рəсмилəштерелə һəм ул кабул ителгəн көннəн алып өч көн эчендə рəис тарафыннан имзалана.